## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Җәмәк торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

№ 2

30 ноябрь 2025

Россия Федерациясенең 20.03.2025 елдагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 45 нче маддә, 69 нчы маддәсе, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Җәмәк торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Җәмәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВО зонасында катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, СВО зонасында катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Җәмәк торак пунктында традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, коймаларны ремонтлау, урнаштыру (материаллар сатып алу, зират коймасын урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, Җәмәк торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (ликвидацияләү, санкцияләнмәгән чүплекләрне барлау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Кадряк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Кадрәк авыл җирлеге башлыгы

Х.Х.Нәбиуллин